# КАРАР

**22 ноябрь 2022 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә 2 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

« Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Иске Оча авылы юлларында чокырларны ямау; проект-смета документлары;; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урам утларын карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү);
- Иске Оча авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 172 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 98 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 98 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: « Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Иске Оча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 800 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Иске Оча авылы юлларны вак таш белән ремонтлау; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урам утларын карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча түләү);
- Иске Оча авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- видеокүзәтү өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру; килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;
- чишмәне, коеларны төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»»

кабул ителгән дип таныргa.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс
авыл җирлеге башлыгы В.Г.Сафаров

ОГРН 1021607753133
ИНН 1623002015